СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (84348) 2-31-00, факс: (8-4348) 2-20-22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-4348) 2-31-00, факс: (84348) 2-20-22

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2026 елның 24 апреленнән — № 9-55

2025 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Яңа Чишмә муниципаль районында җәмәгать ярдәмчесе эшчәнлеге һәм 2026 елга бурычлары турында мәгълүмат

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Яңа Чишмә районы буенча җәмәгать ярдәмчесе Г.М. Рамазанова 2025 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең һәм аның Яңа Чишмә муниципаль районында җәмәгать ярдәмчесенең эшчәнлеге һәм 2026 елга бурычлары турында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең һәм аның Яңа Чишмә муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесенең эшчәнлеге һәм 2026 елга бурычлары турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Яңа Чишмә районы тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча ведомствоара комиссиясенә контроль-күзәтчелек органнары белән берлектә хезмәт хакы буенча бурычларны булдырмау эшен дәвам итәргә тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына һәм «Яңа Чишмә районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУнә тәкъдим итәргә:

- хезмәт законнары таләпләрен үтәмичә, эш бирүчеләр тарафыннан хезмәткәрләрне кыскартуларны булдырмау буенча чаралар күрергә;

- учреждение, оешма, предприятие җитәкчеләре тарафыннан җитештерүдә һәм оешмаларда хезмәтне саклау шартларын һәм куркынычсызлык техникасын үтәү буенча даими эш алып барырга;

-яшь билгесе буенча эшкә кабул иткәндә дискриминацияне кисәтү буенча системалы чаралар күрергә.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә оешмаларның эшенә даими контроль һәм мониторинг ясарга;

- ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән һәм торак белән тәэмин итүдән мәхрүм калган балаларның торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә куелуга һәм аларны торак белән тәэмин итүгә даими контроль үткәрергә;

- балаларга көч куллану очраклары ачыкланган гаиләләрне даими контрольдә тотарга;

- махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә даими мониторингны һәм волонтерлар белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашырырга;

- волонтерларга махсус хәрби операция зонасына һәм Донецк халык республикасы һәм Луганск халык республикаларының шефлык күрсәтелүче территорияләренә гуманитар йөк илтергә ярдәм күрсәтергә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы Е.А.Тарнавский